Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Тураевская средняя общеобразовательная школа»
Менделеевского муниципального района
Республики Татарстан

# Рабочая программа

## *по родной литературе(татарской литературе)*

***для общеобразовательных организации с обучением на татарском языке***

Уровень образования: основное общее образование, 5-9 классы

Разработано: ШМО учителей родного языка (тат) и литературы (тат),
русского языка литературы, иностранного языка (англ.,фран.)

Татарстан Республикасы
Менднлеев муниципаль районы
Муниципаль бюджет гомуми белем бирү  учреждениесе
“Турай урта гомуми белем бирү мәктәбе”

***Татар телендә белем бирү оешмалары өчен***

# әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасы

Белем дәрәҗәсе (сыйныф): төп гомуми белем, 5-9 нчы сыйныфлар

Эшләде:
туган тел(тат) һәм әдәбият(тат),
рус теле һәм әдәбияты,чит тел (инглиз,фран.)
МБ укытучылары

5-9 нчы сыйныфлар өчен әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган «Татар телендә башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”1-11 нче сыйныф өчен.Төзүчесе: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Юсупова, Ф.Ф.Хәсәнова. Казан. 2017, “Одобрено решением федерального учебно - методического объединения по общему образованию (протокол от 16 мая 2017г. № 2/17” нигезләнеп төзелде.

**Дәреслекләр исемлеге:**

| Сыйныф | Дәреслекләр авторы | Нәшрият |
|---|---|---|
| 5 | Ф.Ә. Ганиева, Л.Г. Сабирова | Казан: Татар. кит. нәшр., 2014 |
| 6 | Ф.Ә. Ганиева, М.Д.Гарифуллина | Казан: Татар. кит. нәшр., 2014 |
| 7 | Д.М.Абдуллина,Л.К.Хисмәтова, Ф.Х.Җәүһәрова | Казан: Татар. кит. нәшр., 2014, 2 кисәк |
| 8 | Ф.Ә.Ганиева,Ч.Р. Рамазанова | Казан: Татар. кит. нәшр., 2015, 2 кисәк |
| 9 | Ә.М.Закирҗанов, Г.М.Фәхретдинова | Казан: Татар. кит. нәшр., 2016, 2 кисәк |

Эш программасы **348** сәгатькә исәпләнгән.

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләре
## 5 сыйныф
## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

***Укучыда формалашачак:***

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыру;
- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;

***Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:***

- *гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;*
- *алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.*

## Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып-белү гамәлләре:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;

- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белергә;*
- *укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген кыскартып яки, тулыландырып сөйли белергә;*
- *итә белү (линейка, карандаш, бетергеч…) һәм өстәмә чаралар (информацион һәм коммуникацион технологияләр, белешмә әдәбият һ.б.) куллана белергә;*
- *эш сыйфатына бәя бирә белергә;*
- *уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый һәм ул ситуациядән чыгу юлларын таба белергә.*

**Коммуникатив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;*
- *текст буенча сораулар бирә белү.*

**Регулятив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- укыту проблемасын чишү;
- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *эшчәнлек өчен эш урынын әзерләргә;*
- *укытучы ярдәме белән уку проблемасын табарга һәм формалаштырырга;*
- *укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнергә;*
- *укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерергә.*

## Предмет буенча нәтиҗәләр

### Халык авыз иҗаты

**Укучы өйрәнә**

- һәр жанрга хас үзенчәлекләрне үзләштерү һәм, чагыштырып карап, уртаклык-аермаларын ачыклау;
- нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү; материалны төркемли, гомумиләштерә белү. Һәр жанрга хас үзенчәлекләрне үзләштерү һәм, чагыштырып карап, уртаклык-аермаларын ачыклау;
- нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү;
- материалны төркемли, гомумиләштерә белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *үзешчәнлекне оештыра белү;*
- *башкаларның фикерен тыңлап, уртак фикергә килү,*
- *нәтиҗә ясый алу; әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү.*

**Татар халык әкиятләре**

**Укучы өйрәнә**

- укылганның эчтәлеген тулысынча,кыскача, сайлап һәм иҗади сөйли алу;
- әкиятләрнең төрләрен аера алу; тылсым элементларын күрсәтә белү;
- укыган әкият белән чагыштырып, укучыларның нәтиҗә ясаулары;
- әкиятләрнеңуртаклыгын, аермаларын аңлатулары;
- эчтәлеге ягыннан әкиятләрне аерып, ни өчен шул төргә каравын аңлату.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *халыкның үткән тормышын;*
- *киләчәк турындагы хыял һәм омтылышларын чагылдыра торган, реаль һәм фантастик алымнар белән сурәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша күрсәтелгән халык авыз иҗаты әсәренең әкият булуын үзләштерү.*

**Татар фольклорының лирик һәм лиро-эпик жанрлары: җырлар һәм бәетләр**.

**Укучы өйрәнә**

- җырда халыкның милли характеры, рухи сыйфатлары чагылуын;
- лирик хиснең кичерешләр байлыгы булуын;
- җыр текстларының төзелешен, көй белән гармоник тәңгәллеген үзләштерү, моңлы көйләрне таный алу;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү;

- материалны төркемли, гомумиләштерә белү;
- бәетләрнең үзенчәлекләрен (иҗтимагый вакыйгаларга багышлап, халык тормышының тарихын чагылдырулары;
- алардагы горурлык, ватан кадерен белү хисе;
- шәхси язмышларга багышланганнарында фаҗигале язмышлар кузгаткан әрнү, югалту сагышы;
- көндәлек вакыйгалар турындагы бәетләрдә юмор яки сатира алымнарын куллану, аңлата белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *төрле чыганаклар белән эшли белү: аларны таба, мөстәкыйль рәвештә куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һәм бәяли алу;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*
- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү.*

**Татар фольклорының эпик жанрлары**

**Укучы өйрәнә**

**-** риваятьләр һәм легендаларның үзенчәлекләрен - татар халкының борынгы чорларда ук үз тарихы белән кызыксынуын, дөнья, табигать һәм кешелек турында фикер йөртү дәрәҗәсен чагылдыруын үзләштерү;

- риваять, легендаларда халыкның дөньяга карашы чагылыш табуын, аларның реальлеккә нигезләнүен аңлата алу.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу;*
- *әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган хәзинә буларак кабул итү.*

**Фольклор һәм әдәби әкият. Габдулла Тукай**

**Укучы өйрәнә**

- укылган әсәрләрнең эчтәлеген эзлекле итеп сөйли белү;
- автор позициясен — төп фикер, мәгънәләрне таба, аңлата алу;
- автор сөйләмен, әдәби алым, сурәтләү чараларын күрсәтә белү;
- әсәрне эчтәлеккә тәңгәл килгән интонация белән уку;
- табигать образларында кешеләргә хас сыйфатлар сурәтләнгән урыннарны табып укый һәм, төп фикер-нәтиҗәләрне гомумиләштереп, аңлату.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *соклану, гаҗәпләнү, иркәләнү, үпкәләү, ачулану-ризасызлык белдерү, уйлану-борчылу, шатлану, канәгатьлек белдерү өлкән кеше яки балага хас хис-кичерешләрнең яңгырашы икәнен сүзләрдә күреп, кычкырып укыганда ишетеп кабул итәргә өйрәнү;тормышта конфликтлар килеп чыккан очракта, каршылыкны чишү юлларын табу.*

**Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары**.

**Укучы өйрәнә**

- Ф.Әмирханның татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе, Тукайның замандашы, якын дусты булуын истә калдыру;
- әсәрләренең үзенчәлекләрен: теленең сурәтләү чараларына бай, матур булуын, геройларының кичерешләрен укучы да танып бәяләрлек итеп тасвирлавын;
- «Зөһрә кыз» хикәясендә халык иҗатын сәнгать дәрәҗәсенә күтәреп кую осталыгын аңлау;

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *әхлак нормаларын үзләштерү, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үтәү.*

**Мәсәл жанры. М.Гафури**

**Укучы өйрәнә**

- мәсәлнең аерым бер әдәби жанр икәнен, эпик төргә караганлыгын һәм үзенчәлекле сыйфатларын, язылу формаларын хәтердә калдыру;
- укыган ике мәсәлнең эчтәлеген сөйли алу;
- төп сыйфатларына карап, мәсәлне таный белү;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү; материалны төркемли, гомумиләштерә белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу;*
- *үз карашларыңны раслый һәм дәлилли, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итә белү;*
- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итү.*

**Шигърият. Габдулла Тукай, Ш.Галиев, Ф.Яруллин.**

**Укучы өйрәнә**

- шигырьдә тасвирланган хис-кичерешләрне атый алу;
- текстларны сәнгатьле итеп яттан сөйли белү;
- шигырь төзелешенә караган терминнарны аңлау, аерып күрсәтә алу;
- әдәби алымнарны табып, шулар нигезендә фәлсәфи фикерне ачыклау күнекмәсенә ия булу;
- язу һәм сөйләм осталыгына ирешү, әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта тел-сурәтләү алымнарының, әһәмиятен аңлап бәяләү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *лирик геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү.*

**Халык авыз иҗатында кыска жанрлар**

**Укучы өйрәнә к**

- **к**ыска жанрларны аера, таный белү;
- аларның җанлы сөйләмдә һәм әдәби әсәрләрдә актив кулланылуын; иҗат ителеп торуларын аңлау; мәкаль, табышмак, мәзәкләрдә фикер үткенлеге, тапкырлык, образлылыкның жанр сыйфатлары икәнлеген күрсәтә алу.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;*
- *әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.*

## 6 сыйныф
## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

**Укучыда формалашачак:**

**-** шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану.

***Укучы формалашу өчен мөмкинлек алачак:***

- *әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;*
- *текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*
- *“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек” төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу;*
- *активлыкка, мөстәкыйльлек, иҗади фикер йөртергә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;*
- *үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.*

## Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып-белү гамәлләре:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыру;
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *фикерләүдә логик чылбыр төзү;*
- *тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;*
- *төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;*

**Коммуникатив УУГ:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;*
- *башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;*

*- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;*

*- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.*

**Регулятив УУГ:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;
- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

*укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;*

*- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;*

*- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.*

## Предмет буенча нәтиҗәләр

**Фольклорның эпик жанрларын кабатлау. Мифлар.**

**Укучы өйрәнә**

- халык авыз иҗаты белән матур әдәбиятның бәйләнешләрен - уртаклыгын һәм аермаларын күрә, мисаллар белән дәлилләп аңлата белергә, образлар системасын, характерларны анализлый, аңлата һәм бәя бирергә, укыганны телдән сурәтләп бирергә;
- план төзергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *татар әдәбиятының халык һәм милләт язмышында уйнаган ролен ачыкларга, халык авыз иҗаты әсәрләренең татар әдәбияты формалашудагы ролен аңларга.*

**Әдәбиятта мифик һәм дини сюжетларның үсеше. Каюм Насыйри**

**Укучы өйрәнә**

- әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, анализлый белергә;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйли һәм иҗат иткән чоры белән бәйли белергә;
- -образлар системасын, характерларны анализлый, аңлата һәм бәя бирә алырга.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белергә;*
- *- әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирергә.*

**Фольклор жанрларының әдәби җанрларга күчүе. Гали Рәхим**

**Укучы өйрәнә**

- язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйли һәм иҗат иткән чоры белән бәйли белергә;
- әдәби әсәрнең эчтәлегенә һәм формасына караган төшенчәләрне үзләштереп, әсәрләрне анализлаганда аларны куллана белергә;
- әдәби әсәрнең сюжет элементларын билгели белергә;
- конфликтының чишелешен ачыклап, автор ниятен аңлата белергә;
- образлар системасын, аңлата һәм бәя бирә алырга.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

*- проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белергә;*
*- төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белергә;*
*- вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алырга.*

**Г.Ибраһимов “Алмачуар”**

**Укучы өйрәнә:**

- язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйли һәм иҗат иткән чоры белән бәйли белергә;
- әдәби әсәрнең эчтәлегенә һәм формасына караган төшенчәләрне үзләштереп, әсәрләрне анализлаганда аларны куллана белергә;
- әдәби әсәрнең сюжет элементларын билгели белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә;*
- *әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүмати күзаллау булдырырга.*

**Лирик-эмоциональ образлар. Дәрдмәнд**

**Укучы өйрәнә**

- телнең сурәтләү чараларын, аларның әсәр эчтәлеген ачкандагы ролен ачыкларга;
- әдәби әсәрне анализлаганда, гади әдәби терминология кулланырга;
- лирик төрдәге әсәрләрне анализларга, аларның билгеле бер жанрга каравын белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *әдәби әсәрне, язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализларга, чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи, сәяси һ.б. мәгълүматлар алырга;*
- *телнең төрле сәнгатьле уку, сурәтләү чараларының әһәмиятен аңларга.*

**Һади Такташ. Шигъри образлар**

**Укучы өйрәнә**

**-** шигъри текстларны һәм чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләргә;
- язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйли һәм иҗат иткән чоры белән бәйли белергә;
- лирик төрдәге әсәрләрне анализларга, аларның билгеле бер жанрга каравын белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңларга, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итәргә, әсәрләрдән рухи азык табарга;*
- *әдәби әсәргә, аның өлешләренә, язучы иҗатына карата аңлатмалар, бәя бирергә.*

**Әдәби төр һәм жанрлар**

**Укучы өйрәнә**

- әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алырга, язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләргә;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләргә һәм фикерне исбатларга.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *төрле фикер алышуларда катнашырга, үз фикереңне белдереп,аны тормыш һәм укылган китап белешмәләре белән дәлилләргә.*

**Г.Тукай иҗаты**

**Укучы өйрәнә**

- шигъри текстларны һәм чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләргә;
- язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйли һәм иҗат иткән чоры белән бәйли белергә;
- әдәби әсәрнең эчтәлегенә һәм формасына караган төшенчәләрне үзләштереп, әсәрләрне анализлаганда аларны куллана белергә;

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

*- яңа төшенчәләрнең күләмен билгеләргә, аларны модельләштерергә. Уку эшчәнлеге максаты белән аның мотивы арасындагы бәйләнешне аңларга.*

**Р. Батулла “Имче”**

**Укучы өйрәнә**

- әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализларга; үзенчәлекләрен билгеләргә;
- әсәрләрне үзара чагыштырырга, уртак һәм аермалы якларны таба белергә;
- язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белергә;
- дәреслек материалын тиз һәм урынлы файдаланырга, чагыштыра, гомумиләштерә белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *фикер йөртүнең логик чылбырын язарга.*

**Комик образлар. Галиәскәр Камал**

**Укучы өйрәнә**

- татар реалистик драматургиясенә нигез салучы - Г. Камалның тормышы һәм иҗаты турында сөйли белергә;
- Г.Камалның “Беренче театр ” комедиясендә төп конфликтларны белү;
- мәгърифәтчелек идеяләре, комик чараларны үзләштерү;
- язучының тормыш юлы;
- әдәби әсәрнең эчтәлегенә һәм формасына караган төшенчәләрне үзләштереп, әсәрләрне анализлаганда аларны куллана белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *аралашу мәсьәләсен тормышка ашыру максатында, үз фикереңне белдерергә, үз эшчәнлегеңне оештыру өчен, сөйләмнең төрле чараларыннан нәтиҗәле файдалана белергә.*

**Баллада жанры. Муса Җәлил**

**Укучы өйрәнә**

- телнең сурәтләү чараларын, аларның әсәр эчтәлеген ачкандагы ролен ачыкларга;
- әдәби әсәрне анализлаганда, гади әдәби терминология кулланырга;
- лирик төрдәге әсәрләрнеанализларга, аларның билгеле бер жанрга каравын белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *күмәк фикер алышуга кушыла алырга. Кирәкле мәгълүматны аерып алып, төп һәм ярдәмче мәгълүматны билгели белергә.*

**Эпик төр жанры. Роман.**

**Укучы өйрәнә**

- әдәби әсәрне сюжет-композиция, образлар бирелеше, тел-стиль ягыннан анализларга;
- үзенчәлекләрен билгеләргә; әсәрләрне үзара чагыштырырга, уртак һәм аермалы якларны таба белергә;
- язучыларның әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белергә.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *объектларны классификацияләү, чагыштыру өчен критерийлар сайларга һәм нәтиҗәләр чыгара белергә.*

## 7 сыйныф

## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

**Укучыда формалашачак:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгели алу;
- үз халкыңның тарихы,мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләре тәрбияләү:
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген, милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булу, һөнәр турында җитди караш булдыру;
- әсәрдә гореф- гадәт һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булдыру;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз - үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу,гомумкешелек сыйфатларына ия булу;
- илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисенә төшенү, Ватаныбыз тарихына сакчыл караш тәрбияләү.

***Укучы формалашырга мөмкинлек алачак:***

- *- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ;*
- *- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую);*
- *рухи байлыкның зур бәхет булуын тәрбияләү.*

## Метапредмет нәтиҗәләр

Әдәбиятны иҗтимагый һәм мәдәни тормыш –көнкүрешләре белән бәйлелектә аңлау.

**Танып белү гамәлләре:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-гомум уку гамәлләре (танып белү мәсҗәләсен аңлау,төрле җанрдагы текстлардан кирәкле мәглүматны аерып чыгару,өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү,белемне структуралаштыру,нәтиҗәләр,гомумиләштерүләр ясау);

- логик уку гамәләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән обүектларны анализлау,обүектларны чагыштыру,классификаөияләү критерийларын эшләү,сәбәп –нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү);

- проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәкүбир итү,иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйлҗ эшләү).

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

*- тормыш тәҗрибәсен кулланырга;*

*- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә.*

**Коммуникатив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

-хезмәттәшлек итү;

- тел нормаларына туры китереп,монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;

- үз фикерләрен тәгъбир итү;

- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;

- фикерләрне дәлилләп җиткерү;

- сәнгатьле уку күнекмәләрен *үстерү.*

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

*-- төрле фикерләр һәм карашлар арасында аермалыкларны аңларга, шул фикерләрнең берсенә кушылырга һәм ни өчен икәнлегенең сәбәбен дәлилләргә;*

*--текстан геройлар әйткән фикерләрнең дөреслеген дәлилли торган фикерләрне табарга.*

*- фикерләрне эзлекле рәвештә,мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру.*

**Регулятив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- уку мәсьәләсен кую;
- фаразлау;

- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *үзенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контрольдә тотып бәяди алу;*
- *үзанализ һәм үзбәя ясау.*

## Предмет буенча нәтиҗәләр

**Сәнгать төре буларак әдәбият. Халык авыз иҗаты. Дастан. «Идегәй» дастаны**

**Укучы өйрәнә**

- әдәбиятның тормышны сурәтләүдә нинди сәнгать чараларына мөрәҗәгать итүен күзәтеп, образлы фикерләү мөмкинлеген арттыру; тарихи дастан “Идегәй”не өйрәнү, образлар системасын анализлау.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү; төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү. Дастан жанры турында мәгълүматны үзләштерү, аның югары идеялелеген, сәнгати камиллеген бәяләү;*
- *фикер алышуның төрле төрләрендә катнашканда, үз фикереңне дөрес формалаштырып әйтә белү, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, аргументлар китерә алу;*
- *әдәби әсәрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга; әдәби әсәрләрнең эстетик кыйммәтен, төрен һәм жанрын билгеләргә, әдәби текстны анализларга, бәхәсләрдә оппонентларның фикерләрен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә; рефератлар, докладлар әзерләргә; әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинениеләр язарга; рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә; әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү алга куела.*

**Матур әдәбиятнең эпик төре. Эпик жанрлар**.

**Укучы өйрәнә**

- XX гасыр башы әдәбиятының үзенчәлекләрен билгеләү һәм әдәби үсештә гаять бай дәвер булуын тану;
- Н.Думави иҗаты һәм «Яшь ана» хикәясенең әдәби кыйммәтен ачыклау;
- Әдәбиятта «Акчарлаклар» повестеның урынын билгеләү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *өйрәнелгән әсәрләрне мөстәкыйль шәрехли белүгә ирешү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;*
- *үз фикереңне дәлилле, кирәк булганда, үзгәртә-төгәлли, нәтиҗәләр чыгара белү;*

- *максатларга ирешү юлларын мөстәкыйль рәвештә планлаштыру, шул исәптән альтернативларын, аеруча нәтиҗәле уку юлларын һәм танып-белү бурычларын аңлы рәвештә сайлау мөмкинлеге;*
- *тикшеренү эшчәнлеге: әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау; тулы текстны анализлау;*
- *төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;*
- *әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.*

**Әдәбиятның лирик төре. Лирика һәм лиро-эпика.**

**Укучы өйрәнә**

- материалны төркемли, үз фикереңне дә-лилли, нәти-җәләр чыгара, өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;
- герой-ларның, әхла-кый идеаллар-ның охшаш һәм аермалы якларын бил-геләү күнекмә-сенә ия булу;
- материалны гомумиләштерә белү, әдәби алымнарны табып, шулар нигезендә фәл-сәфи фикерне ачыклау күнек-мәсенә ия булу;
- язу һәм сөйләм осталыгына ирешү. Шигырьнең диалогка корылганлыгы. Милләткә эндәшү, үз халкыңа мәхәббәтне ассызыклау. Лирика, гражданлык лирикасы турында мәгълүматлы булу.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу;*
- *әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү.*

**XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты**

**Укучы өйрәнә**

- XX икенче яртысында татар әдәбиятының үзенчәлекләрен билгеләү.
- С.Хәким, Ә.Еники, М.Мәһдиев, З.Хәким, Ш.Хөсәенов, Г.Гыйльманов, Г.Сабитовның тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу;
- -әсәрдә булган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә һәм аера белү;
- хәзерге чорда язылган әдәби әсәрләр буенча ясалган эзләнү эшләрен яклау;
- жанр үзенчәлекләрен искә төшерү, анализ алымнарын кабатлау;
- хикәя, драма жанрына хас үзенчәлекләрне күрә, аера белү, әсәрнең тема, проблема, идеясен билгели белү.
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *XX гасырның икенчеяртысында татар әдәбиятын илдәге сәяси-тарихи вакыйгалар белән бәйләп өйрәнү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*

- *әхлак нормаларын үзләштерү, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үтәү;*
- *әсәрләрнең эчтәлеген үзләштерү аша сәнгатьчә эшләнеш үзенчәлеген аңлау.*

## 8 сыйныф
## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

**Укучыда формалашачак:**

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;

***Укучы формалашырга мөмкинлек алачак:***

- *баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;*
- *әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;*

*төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.*

## Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып-белү гамәлләре:**

**Укучы өйрәнә:**

- укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;
- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.*

**Коммуникатив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгеле, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;

- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.*

**Регулятив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнәчәк:**

- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру;
- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү.

***Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак:***

- *баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;*
- *рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү;*
- *мәгълүматлар табарга күнектерү.*

## Предмет буенча нәтиҗәләр

**Кабатлау. Матур әдәбиятның лирик, эпик һәм драматик төрләре**

**Укучы өйрәнә:**

- нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләш-терә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта баш-калар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;
- узган сыйныфларда өйрәнгән әсәрләр мисалында лирик, эпик, драматик төрләрне кабатлау, гомумиләштерү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү;*
- *өйрәнелгән әсәрләрнең төрләрен белүгә ирешү;*
- *әдәби әсәр төрләренең охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү.*

**Матур әдәбиятта үгет-нәсыйхәт бирү**. **Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятына гомуми характеристика**

**Укучы өйрәнә:**

- «Нэсыйхэт» шигырендэге дини-суфичыл фикерлэрне билгели алу, автор позициясен ачыклау һэм аңа үз мөнэсэбэтеңне булдыру күнекмэсенэ ия булу;
- эдэби текстны тел-сурэтлэү алымнарының, образлылыкның үзенчэлеклэрен һэм эһэмиятен аңлап бэяли белү.

***Укучы өйрэнергэ мөмкинлек ала:***

- *төрле чыганаклар белэн эшли белү: аларны таба, мөстэкыйль рэвештэ куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һэм бэяли алу;сүз сэнгатен халыкның яшэү рэвешен, рухи кыйммэтлэрен саклап калган һэм беркетэ килгэн хэзинэ буларак кабул итү.*

**Белемле һэм гыйлемле кеше концепциясе, аны сүрэтлэү үзенчэлеклэре.**

**Укучы өйрэнэ:**

- укыган эдэби эсэрнең эчтэлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һэм эдэби дөньясын бэяли алу, аның нинди төр һэм жанрга ка-равын аеру;
- автор позициясен ачыклый алу һэм аңа үз мөнэсэбэтеңне булдыру күнекмэсенэ ия булу;
- мэгърифэтчелек эдэбияты үрнэге буларак, стиль үзенчэлеклэрен күрсэтэ белү.

***Укучы өйрэнергэ мөмкинлек ала:***

- *өйрэнелгэн эсэрлэрне шэрехли белүгэ ирешү;*
- *геройларның, эхлакый идеалларның охшаш һэм аермалы якларын билгелэү күнекмэсенэ ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мэгълүматлар таба белү;*
- *милли эдэбияттагы рухи-эхлакый кыйммэтлэрне күңел аша уздырып кабул итэргэ өйрэнү.*

**Мэҗит Гафуриның “Нэсыйхэт” шигыре.**

**Укучы өйрэнэ:**

- Мөхэммэдьяр һэм М.Гафури-ның “Нэсый-хэт” эсэрлэрен чагыштыру аша, эдэбиятта традиция һэм яңалык турында нэтиҗэ ясауга ирешү;
- Мөхэммэдьяр һэм М. Гафуриның “Нэсыйхэт” эсэрлэрен һэм Г. Тукайның дини темага язылган шигырьлэрен чагыштыру аша, эдэбиятта традиционлык турында нэтиҗэ ясый белү.

***Укучы өйрэнергэ мөмкинлек ала:***

- *нэтиҗэлэр чыгара, материалны гомумилэштерэ белү, үз хислэреңне сүзлэр ярдэмендэ аңлата алу һэм бер үк вакытта башкалар белэн бергэлэп эшлэү күнекмэлэренэ ия булу;*
- *эхлак нормаларын, җэмгыятьтэ яшэү кагыйдэлэрен үзлэштерү.*

**Эдэбиятты психологизм.Шэриф Камал “Буранда”.**

**Укучы өйрэнэ:**

- материалны төркемли, үз фикереңне дэлилли, нэтиҗэлэр чыгара, өйрэнелгэн эсэрлэрне шэрехли белүгэ ирешү; геройларның, эхлакый идеалларның охшаш һэм аермалы якларын билгелэү күнекмэсенэ ия булу;
- материалны гомумилэштерэ белү, эдэби алымнарны табып, шулар нигезендэ фэлсэфи фикерне ачыклау күнекмэсенэ ия булу;
- язу һэм сөйлэм осталыгына ирешү.

***Укучы өйрэнергэ мөмкинлек ала:***

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу;*
- *әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү.*

**Фатих Әмирханның “Бер хәрабәдә” хикәясе**

**Укучы өйрәнә:**

- хикәянең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;
- әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта тел-сурәтләү алымнарының, әһәмиятен аңлап бәяли белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *өйрәнелгән әсәрләрне мөстәкыйль шәрехли белүгә ирешү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;*
- *үз фикереңне дәлилли, кирәксә- үзгәртә-төгәлли, нәтиҗәләр чыгара белү.*

**Татар әдәбиятында романтик стиль.  Фәтхи Бурнаш “Таһир-Зөһрә”.**

**Укучы өйрәнә:**

- әдәби әсәрне аңлап уку, мөстәкыйль үзләштерү күнекмәләренә ия булу;
- трагедиянең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, әсәрнең кайсы төр һәм жанрга каравын аера белү;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белү;
- материалны төркемли, гомумиләштерә белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу;*
- *үз карашларыңны раслый һәм дәлилли, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итә белү;*
- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итү.*

**Һади Такташның “Алсу”, Гадел Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”, Кәрим Тинчурин“Сүнгән йолдызлар”**

**Укучы өйрәнә:**

- укыган әдәби әсәрнең эчтәле-ген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, аның кайсы төр һәм жанрга каравын аеру;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;
- әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының үзенчәлекләрен, әһәмиятен аңлап бәяли белү;

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *әхлак нормаларын үзләштерү, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үтәү*

**Татар әдәбиятында патриотлылык. Фатих Кәрим**

**Укучы өйрәнә:**

- пафос белән, логик басымнарны шигырьдәге мәгънәләргә туры килерлек итеп куеп, тиешле урында паузалар ясап укуга ирешү;
- образларны күрсәтеп, алар арасындагы бәйләнешләрне аңлата алу;
- фикер һәм хис тәңгәллеген, сурәтләү чараларын анализлый белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *Бөек Ватан сугышының максатларын, характерын һәм анда катнашкан халыкларның сугышка мөнәсәбәтен истә тотып, Бөек Җиңүнең кыйммәтен бәяли алу;*
- *Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән әдәбиятның үзенчәлекләрен күрсәтә белү.*

**Фәнис Яруллин “Җилкәннәр җилдә сынала”, Равил Фәйзуллин “Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...”, Татар әдәбиятында тормыш фәлсәфәсе. Туфан Миңнуллин, Мөдәррис Әгъләмовның “Каеннар булсаң иде”**

**Укучы өйрәнә :**

- әсәрнең язылу вакытына игътибар итеп, сугыш чоры тудырган авырлык, фаҗигаләр һәм аларның сәбәпләре турында аңлата белү;
- әсәрнең исеменә салын-ган күчерелмә мәгънәне вакыйгалар белән бәйли, табигать белән тәңгәл килгән матурлыкны – әсәрнең поэтикасын, сәнгатьлелек чараларын анализлый белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу.*

## 9 сыйныф
## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

**Укучыда формалашачак:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгели алу;
- үз халкыңның тарихы,мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләре тәрбияләү;
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген,милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булу,һөнәр турында җитди караш булдыру;
- әсәрдә гореф- гадәт һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булдыру;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз - үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу,гомумкешелек сыйфатларына ия булу;

***Укучы формалашырга мөмкинлек алачак:***

- *илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисенә төшенү, Ватаныбыз тарихына сакчыл караш тәрбияләү;*
- *рухи байлыкның зур бәхет булуын тәрбияләү.*

## Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып белү гамәлләре:**

**Укучы өйрәнә**

-гомум уку гамәлләре (танып белү мәсҗәләсен аңлау,төрле ңанрдагы текстлардан кирәкле мәглүматны аерып чыгару,өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү,белемне структуралаштыру,нәтиҗәләр,гомумиләштерүләр ясау);

- логик уку гамәләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән обүектларны анализлау,обүектларны чагыштыру,классификаөияләү критерийларын эшләү,сәбәп –нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү).

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

*- проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәкүбир итү,ижҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйлж эшләү).*

**Коммуникатив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнә:**

-хезмәттәшлек итү;
- тел нормаларына туры китереп,монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;
- үз фикерләрен тәгъбир итү;
- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;
- фикерләрне дәлилләп җиткерү;
- сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала****:*

*- фикерләрне эзлекле рәвештә,мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру.*

**Регулятив гамәлләр:**

**Укучы өйрәнә:**

- уку мәсәләсен кую;
- фаразлау;
- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү;
- үзенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контролжҗә тотып бәяди алу;
- үзанализ һәм үзбәя ясау.

## Предмет буенча нәтиҗәләр

**Сәнгать төре буларак әдәбият**

**Укучы өйрәнә:**

- нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;
- узган сыйныфларда өйрәнгән әсәрләр мисалында XX гасыр башы татар әдә-биятының сүз сәнгате буларак үзенчәлекләрен билгели алу.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү;*
- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү; геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү.*

**Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият**

**Укучы өйрәнә:**

- төрки халыклар, татарларның борынгы бабалары турында тарихи-әдәби мәгълуматларны өйрәнү;
- борынгы, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының үсеш этапларын белү;
- татар әдәбиятының бер өлеше буларак гомумтөрки әдәбияты һәм фольклорын, Орхон-Енисей истәлекләрен, аларда борынгы төрки халыкларының тарихы, ышануы, әдәби фикерләү үзенчәлекләренең чагылышын өйрәнү;
- М.Кашгариның “Диване лөгат эт-төрк” әсәре.Й.Баласагунлы “Котадгу белек”–төрки халыкларының беренче классик поэмасын өйрәнү;
- XII-XIII гасырларда Болгар-татар әдәбияты, К.Гали “Кыйссаи Йосыф”-кеше хисләренең бөеклеге, матурлык, зирәклек гимны булуын ачыклау;
- татар әдәбиятында Яңарыш чоры буларак Алтын Урда әдәбияты . Котб, Сәиф Сараи, Хәрәзми иҗатын белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *төрле чыганаклар белән эшли белү: аларны таба, мөстәкыйль рәвештә куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һәм бәяли алу;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*
- *төрки-татар әдәбиятында суфичылык юнәлеше;*
- *Казан ханлыгы чоры әдәбиятына гомуми бәяләмә. Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуы. М.Колыйның фәлсәфи-дидактик хикмәтләрендә татар җәмгыятенең кризис хәленең чагылуы;*
- *дини-суфичыл фикерләрне билгели алу, автор позициясен ачыклау һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;*
- *әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белү.*

**XIX гасыр татар әдәбияты**.

**Укучы өйрәнә:**

- Г.Курсави, И.Хәлфин, К Насыйри, Ш.Мәрҗәни, Х.Фәизханов, И.Гаспринскийның мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән танышу;
- Г.Кандалый, Акмулла иҗатында реалистик поэзия формалашу этапларын күзәтү. Татар реалистик прозасы формалашуны күзәтү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү.*

**Әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү**

**Укучы өйрәнә:**

- әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килүне белү;
- З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын уку һәм анализлау. Татар халкының үсеш яңарыш кичерүе өчен, мондый темаларның актуаль булуы, татар хатын-кызы язмышы, рус мәдәниятенә йөз тотуны күзәтү, тиешле нәтиҗә ясый белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;әхлак нормаларын, җәмгыятьт тә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.*

**20 гасыр башы татар әдәбияты.**

**Укучы өйрәнә :**

- сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүен күзәтү.
- Ф.Әмирханның. «Хәят» повестен уку һәм анализлау.
- Модернизм, модернизм алымнарын өйрәнү. Материалны төркемли, үз фикереңне дәлилли, нәтиҗәләр чыгара, өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;
- геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу. Г.Камал "Банкрот" әсәрен өйрәнү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу; әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;*
- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү, әдәби алымнарны табып, шулар нигезендә фәлсәфи фикерне ачыклау күнекмәсенә ия булу;*
- *язу һәм сөйләм.*

**XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты**

**Укучы өйрәнә:**

- 1917 елдан соңгы татар әдәбияты үсешендә очраган кыенлыкларны күзәтү;
- эпик төр буларак роман жанрының активлашу этапларын белү;

- М.Галәү “Мөһаҗирләр” романын өйрәнү.Романның  эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;
- әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта тел-сурәтләү алымнарының, әһәмиятен аңлап бәяли белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***:

- *өйрәнелгән әсәрләрне мөстәкыйль шәрехли белүгә ирешү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;*
- *үз фикереңне дәлилле, киләксә- үзгәртә-төгәлли, нәтиҗәләр чыгара белү.*

**Бөек Ватан сугышының әдәбиятка йогынтысы**

**Укучы өйрәнә:**

- сугыш еллары поэзиясенең төп тема-мотивлары, образлары, поэтикасын белү.
- Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнү;
- Муса Җәлилнең “Тик булса иде ирек”, “Җырларым” шигырьләрен өйрәнү.М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗатын белү;
- Ә.Еникинең “Кем җырлады” хикәясен өйрәнү. Шигырьләрне  тиешле интонация, пафос белән, логик басымнарны шигырьдәге мәгъ-нәләргә туры килерлек итеп куеп, тиешле урында паузалар ясап укуга ирешү;
- образларны күрсәтеп, алар арасындагы бәйләнешләрне аңлата алу;
- фикер һәм хис тәңгәллеген, сурәтләү чараларын анализлый белү. Әсәрнең язылу вакытына игътибар итеп, сугыш чоры тудырган авырлык, фаҗигаләр һәм аларның сәбәпләре турында аңлата белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *Бөек Ватан сугышының максатларын, характерын һәм анда катнашкан халыкларның сугышка мөнәсәбәтен истә тотып, Бөек Җиңүнең кыйммәтен бәяли алу;*
- *Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән әдәбиятның үзенчәлекләрен күрсәтә белү.*

**XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты**

**Укучы өйрәнә:**

- XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуын күзәтү;
- А.Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» повестен өйрәнү. Татар әдәбиятының милли традицияләргә кайтуы, тарихи роман жанры барлыкка килүен күзәтү. Н. Фәттахның  “Ител суы ака торур» романын уку.Әсәрнең  исеменә салынган күчерелмә мәгънәне вакыйгалар белән бәйли, табигать белән тәңгәл килгән матурлыкны – әсәрнең поэтикасын, сәнгатьлелек чараларын анализлый белү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *Өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*
- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*
- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*
- *әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу.*

**XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты**. **Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары. Халык традицияләрен саклау һәм яңарыш проблемалары**

**Укучы өйрәнә:**

- XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятының үзгәрүе: совет һәм аннан соңгы чорга тәнкыйди бәя бирергә өйрәнү;
- Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләрен өйрәнү. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы күзлегеннән ил тормышының аерым этапларын сурәтләүче әдәби әсәрләрнең барлыкка килүен күзәтү;
- Ф.Садриевның «Таң җиле» романын уку һәм анализлый алу;
- Т.Миңнуллин "Кулъяулык" әсәрен өйрәнү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***

- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*
- *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*
- *әхлак нормаларын үзләштерү, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үтәү. Укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, аның кайсы төр һәм жанрга каравын аеру;*
- *автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнек-мәсенә ия булу;*
- *әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының үзенчәлекләрен, әһәмиятен аңлап бәяли белү.*

## Уку материалының эчтәлеге
## 5 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Халык авыз иҗаты** | Татар халкының милли, рухи мәдәниятенең байлыгы буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең мөһим өлеше буларак гомумкешелек кыйммәтләре. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә образлар системасы. Фольклорда дөнья картинасы: геройлык, игелек һәмявызлык, тормыш һәм кеше, кеше һәм табигать турында күзаллау. Фольклор әсәрләренең шигъри үзенчәлекләре: чагыштыру, гәүдәләнеш, метафоралылык , аллегориялелек. | 4 |
| 2. | **Кыска фольклор жанрлары** | Кыска фольклор жанрлары. Мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар һәм мәзәкләр. Халык психологиясе, фольклор әсәрләрендә идеаллар һәм кузаллаулар | 4 |
| 3. | **Татар фольклорының лирик һәм лиро-эпик жанрлары: җырлар һәм бәетләр** | Татар фольклорының лирик һәм лиро-эпик жанрлары: җырлар һәм бәетләр. Лирик, тарихи, йола җырлары, такмаклар, мөнәҗәтләр, татар халык җырларының үзенчәлекләре («Иске кара урман» җыры). Татар фольклорының үзенчәлекле жанры – бәет. "Сак-Сок». Жанр формалаштыру алшартлары. Аларның төрләре . | 6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | **Татар фольклорының эпик жанрлары** | Татар фольклорының эпик жанрлары: риваятьләр һәм легендалар («Зөһрә кыз» легендасы һәм «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган» риваятьләре). | 6 |
| 5. | **Татар халык әкиятләре** | Татар халык әкиятләре (1-4 классларда өйрәнелгәнне кабатлау) Әкиятләр, төрләре (тылсымлы әкият «Ак бүре"»). Көнкүреш әкиятләре. Хайваннар турында әкиятләр. Фольклор әсәрләренең поэтикасы(аерым детальләрдә фантастик яки мифологик сюжет, тормышчанлык, кабатлау, гипербола, литота,каршы кую( антоним) кебек сәнгать алымнарын куллану) | 10 |
| 6. | **Героик эпос** | Героик эпос. Дастан жанрының характерлы билгеләре. | 6 |
| 7. | **Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары** | Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары. Әдәбият барлыкка килү, татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнеше (Ф. Әмирхан «Ай өстенә Зөһрә кыз»). Игелек һәм явызлык гәүдәләндерү. Текстта персонажлар системасы. Бара торган вакыйгаларга автор аңлатмалары | 4 |
| 8. | **Фольклор һәм әдәби әкият** | Фольклор һәм әдәби әкият (Г. Тукай «Шүрәле»). Сәнгать уйдырмалары (вымысел). Троп. | 6 |
| 9. | **Габдулла Тукай** | Габдулла Тукай, романтик шигырьләрдә («Пар ат»,«Туган җиремә» )туган җиргә дан җырлау. Казанга сәфәрне әкияти рәвештә торгызу. Казан һәм туган җир мифологиясе. Лексик һәм фонетик нәфис сүз чаралары. | 5 |
| 10. | **М.Гафури** | М.Гафури. «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле. Мәсәлнең жанры. Аллегорик образлар. | 4 |
| 11. | **Ш.Галиев** | Ш.Галиев. «Һәркем әйтә дөресен»<br>Балалар әдәбияты. Юмор, сатира. | 4 |
| 12. | **Ф.Яруллин** | Ф.Яруллин. «Сез иң гүзәл кеше икәнсез»<br>Ритм, рифма, шигырь, строфа. Шигырь төзелеше | 4 |
| 13. | **Кабатлау** | Кабатлау һәм гомумиләштерү<br>5 сыйныфта өйрәнгәнәрне кабатлау | 7 |
| **Барлыгы** | | | 70 |

## 6 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Фольклорның эпик жанрларын кабатлау** | Фольклорның эпик жанрларын кабатлау (бәетләр,әкиятләр, риваятьләр, легендалар), метафоралылык, аллегориялелек. | 4 |
| 2. | **Мифлар** | Мифлар. Мифлар барлыкка килү концепциясе. Мифларны классификацияләү. Татар халык мифлары. Татар халык мифлары (“Алып кешеләр”, “Җил иясе җил чыгара”) | 2 |
| 3. | **Әдәбиятта мифик һәм дини сюжетларның үсеше** | Әдәбиятта мифик һәм дини сюжетларның үсеше. Каюм Насыйриның фәнни һәм әдәби эшчәнлеге. Аның фольклор,этнография, әдәбият, татарлар тарихын өйрәнүе. К.Насыйриның “Әбүгалисина ”. Повестьта фантастик сюжет һәм мәгърифәтчелек идеяләре. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Фикерләү өчен тема. Әбүгалисина образы – тарихи персонажмы, әкият героемы әллә мәгърифәтчелек идеалымы? | 10 |
| 4 | **Фольклор жанрларының әдәби җанрларга күчүе** | Фольклор жанрларының әдәби җанрларга күчүе: шартлылык (Г.Рәхим “Яз әкиятләре”). Аллегорик образлылык. Персонаж-хикәяләүче исеменнән сөйләү. Мөһим кешелек сыйфаты буларак, риясызлык. | 4 |
| 5 | **Г.Ибраһимов** | Г.Ибраһимов. Гади халык тормышының матурлыгына, яшәешенең гармониясенә, әхлакый тулылыгына дан җырлау. | 6 |
| 6 | **Г.Тукай** | Г.Тукай. “Исемдә калганнар” автобиографик повесть. Хикәяләүче образы: кечкенә Апуш һәм шагыйрь Габдулла. Характер. Хатирәләр, шартлылык, уйдырма. | 6 |
| 7 | **Р. Батулла “Имче”** | Р. Батулла “Имче”. Г. Тукайның балачагы турында тарихи сюжет. Батулла героеның Тукайның Апушы белән охшаш һәм аермалы яклары. Тарихи ситуацияләр тудыру алымнары. Хикәяләү үзенчәлекләре. | 6 |
| 8 | **Комик образлар** | Комик образлар. Татар реалистик драматургиясенә нигез салучы - Г. Камалның тормышы һәм иҗаты. Г.Камалның “Беренче театр ” комедиясендә төп конфликтлар. Мәгърифәтчелек идеяләре, комик чаралар. | 6 |
| 9 | **Лирик-эмоциональ образлар** | Лирик-эмоциональ образлар. Дәрдмәнд “Витагъ”. Лирик текст эчтәлеге, лирик герой, хис-кичерешләр. Табигать образлары - лирик геройның күңелен ачу чарасы. Пейзаж лирикасының фәлсәфи мәгънәсе, аларның символикасы. Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. Дәрдмәнд турында татар әдәбияты. | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | **С. Рәмиев “Уку”** | С. Рәмиев “Уку”. Уку мотивы. Автор образы. Гражданлык лирикасы. С. Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗаты. С. Рәмиев турында татар әдәбияты. | 4 |
| 11 | **Һ. Такташ** | Һ Такташ “Пи –би-бип” Туган җир һәм табигать образы. | 4 |
| 12 | **Муса Җәлил** | Муса Җәлил “Сандугач һәм Чишмә”. Шартлылык һәм аллегория. | 4 |
| 13 | **Кабатлау** | Кабатлау һәм гомумиләштерү<br>5 сыйныфта өйрәнгәнәрне кабатлау | 6 |
| **Барлыгы** | | | 70 |

**7 сыйныф**

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Кабатлау** | Кабатлау: образлар системасы. Деталь һәм образ | 4 |
| 2. | **«Идегәй» дастаны** | «Идегәй» дастанының кыскача эчтәлеге, проблематикасы, төп героилары һәм сәнгатьчә үзенчәлеге. Фикер алышу өчен тема. Эпос каһарманнары, милли һәм кешелек сыйфатлары | 6 |
| 3 | **Матур әдәбиятнең эпик төре. Эпик жанрлар** | Матур әдәбиятнең эпик төре. Эпик жанрлар. Хикәя жанры. Н. Думави “Яшь ана”. Кыз һәм үги ана мөнәсәбәтләренең татар әдәбияты өчен традицион булмаган сюжеты. Үги ана образына салынган мәгънәви басым. Әсәр теле һәм интонациясенең үзенчәлеге | 6 |
| 4 | **Повесть жанры. Ш.Камал** | Повесть жанры. Ш.Камал. “Акчарлаклар”. Чит җирдә бәхет эзләргә мәҗбүр булу проблемасы. Драматизм. Сәнгатьле сөйләм: хикәяләү, диалог, монолог. | 8 |
| 5. | **Повесть жанры . Ә.Еники** | Повесть жанры . Ә.Еники.<br>Милли һәм социаль проблематика: татар милләтенең язмышы, җәмгыятьтә әһлакый кыйммәтләренең югалуы турында уйланулар.<br>Эпиграф, багышлау, көчле позитция.<br>Ә.Еникиның тормыш юлы һәм иҗаты. | 6 |
| 6. | **Повесть жанры . М. Мәһдиев “Без – кырык беренче ел балалары”** | Повесть жанры . М. Мәһдиев “Без – кырык беренче ел балалары”.<br>Татар прозасында лиризм, орнаментализм. Лирик чигенүләр.<br>Әдәбият үсешенең төрле чорларында мотив һәм темаларның кабатлануы. XX гасыр башы, XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында милләт язмышы мотивы. | 8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | **Әдәбиятның лирик төре. Лирика һәм лиро-эпика. Г. Тукай “Милләтә”** | Әдәбиятның лирик төре. Лирика һәм лиро-эпика. Г. Тукай “Милләтә”. Шигырьнең диалогка корылганлыгы. Милләткә эндәшү, үз халкыңа мәхәббәтне ассызыклау. Лирика, гражданлык лирикасы. Фикерләшү өчен тема: “Г. Тукай иҗатында милләт язмышы темасы”. | 3 |
| 8. | **С.Хәким** | С.Хәким.<br>Тел – стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар).<br>«Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Туган як образын мифлаштыру.<br>Лиризм һәм өлкән буын шагыйрьләр иҗатында сәнгать, әдәбият, тарихи тәҗрибәне социаль-фәлсәфи яктан аңлау. Лириканы психологик детальләр белән тутыландыру. С.Хәкимнең “күңел” лирикасы. | 3 |
| 9. | **Драматик жанрлар** | Драматик жанрлар. Әдәбиятның драматик жанрлары. Татарларда драматик төрнең барлыкка килү тарихы. XX гасыр башы татар җәмгыятендә туган комик ситуацияләрне сүрәтләү: аерым кешеләрнең, рус, европа дөньясының тышкы атрибутларын үзендә булдырып, белемле, затлы булып күренергә тырышуы, үз тамырлары һәм телләреннән ваз кичүләре. Сатира һәм ирония. | 8 |
| 10. | **Ш.Хөсәенов** | Ш.Хөсәенов “Әни килде”. Социаль-этик проблематика. Образ, символ, архетип. Проза һәм драматургияда “критик юнәлеш” формалашу | 8 |
| 11. | **Татар әдәбиятында бәхет мотивы. Г. Сабитов** | Татар әдәбиятында бәхет мотивы. Г. Сабитов “Тәүге токлану”. Хикәянең сюжеты, авыл тормышы күренешләре. Көнләшү чагылышы нәтиҗәсе буларак конфликт. Балачак һәм үткәннәрне сагыну (ностальгия). Сөйләүче малай һәм автор хикәяләүче. Вакыйга, подтекст, контекст. Алтын балык, ак болытлар символы. Фикерләшү өчен тема. “ Нәрсә ул бәхет?” | 3 |
| 12 | **Г. Гыйльм** | Г. Гыйльманов “Язмышның туган көне”. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Фикерләшү өчен тема. “Могҗиза көтү тойгысы сезгә танышмы?” | 3 |
| 13 | **Кабатлау** | 7 нче сыйныфта үтелгәннәрне кабатлау һәм гомумиләштерү | 4 |
| **Барлыгы** | | | 70 |

**8 сыйныф**

| **№** | **Бүлекләр исеме** | **Эчтәлек** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | **Кабатлау** | Кабатлау: матур әдәбиятның лирик, эпик һәм драматик төрләре | 2 |
| 2. | **Матур әдәбиятта үгет-нәсыйхәт бирү. Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятына гомуми характеристика** | Матур әдәбиятта үгет-нәсыйхәт бирү. Казан ханлыгы чоры татар әдәбиятына гомуми характеристика ( Мөхәммәт Әмин, Колшәриф,Өмми Камал). Мөхәммәдьяр иҗатында гуманлылык мотивлары. “Нәсыйхәт” шигыре. | 3 |
| 3 | **Белемле һәм гыйлемле кеше концепциясе, аны сүрәтләү үзенчәлекләре** | Белемле һәм гыйлемле кеше концепциясе, аны сүрәтләү үзенчәлекләре. (Муса Акъегет “Хисаметдин менла” повесте). Белемле,әхлаклы,мәрхәмәтле,тәрбияле, , аңлылык, гаделлек акыл патриотизм һәм затлылык. Геройга автор характеристикасы. Геройның әхлакый сайлавы. Милләтнең идеал сыйфатларының Хисаметдин образында туплануы. | 2 |
| 4 | **Мәҗит Гафуриның “Нәсыйхәт” шигыре** | Мәҗит Гафуриның “Нәсыйхәт” шигыре. 20 нче гасыр башында шагыйрь иҗатында яхшылык һәм яманлык темасы. Традицияләр һәм яңачалык. | 3 |
| 5 | **Әдәбиятты психологизм.Шәриф Камал “Буранда”** | Әдәбиятты психологизм.Шәриф Камал “Буранда”. Текстның эмоциональ тулылыгы: алымнар һәм ысуллар. Композитция. | 4 |
| 6 | **Фатих Әмирханның “Бер хәрабәдә” хикәясе** | Фатих Әмирханның “Бер хәрабәдә” хикәясе . Нәсер жанры. Хикәяләүче образы, аның эчке кичерешләре. Символлар, кабатлаулар, текстның аһәңе. Геройларның исемнәре. | 4 |
| 7 | **Татар әдәбиятында романтик стиль** | Татар әдәбиятында романтик стиль. Фәтхи Бурнаш “Таһир-Зөһрә”. Трагедия жанры. Әсәрдә мәхәббәт һәм мәкер темасы. Урта гасыр әсәрләрендә романтик сюжет, мәхәббәт һәм хыянәт темасы. | 8 |
| 8 | **Һади Такташның “Алсу”** | Һади Такташның “Алсу” . Поэма жанры. Поэмада романтик геройның сурәтләнеше. | 3 |
| 9 | **Гадел Кутуй “Тапшырылмаган** | Гадел Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”. Әсәрнең романтик сюжетка корылган булуы. Соцреализм рухындагы урыннар. | 6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **хатлар”** | | |
| 10 | **Кәрим Тинчурин“Сүнгән йолдызлар”** | Кәрим Тинчурин“Сүнгән йолдызлар”. Әсәр исеменең афоризмлылыгы.  Әсәрдә мәхәббәт темасы. | 6 |
| 11 | **Татар әдәбиятында патриотлылык. Фатих Кәрим** | Татар әдәбиятында патриотлылык. Фатих Кәрим “Сибәли дә сибәли” шигыре. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясендә патриотлылык темасы. Шигырьгә анализ ясау. Шигырьдә геройны сугыш фаҗигасен тасвирлаган табигать күренешләре аша тасвирлау. | 4 |
| 12 | **Фәнис Яруллин “Җилкәннәр җилдә сынала”** | Фәнис Яруллин “Җилкәннәр җилдә сынала”.  Фәниярнең язмыш сынауларына каршы бара алуы һәм аны җиңүе. | 8 |
| 13 | **Равил Фәйзуллин “Җаныңныңваклыгын сылтама заманга...” шигыре** | Равил Фәйзуллин “Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...” шигыре | 2 |
| 14 | **Татар әдәбиятында тормыш фәлсәфәсе. Туфан Миңнуллин** | Татар әдәбиятында тормыш фәлсәфәсе. Туфан Миңнуллин “Әлдермештән Әлмәндәр”. Әдәбиятта “көчле кеше” образы. Үлемне  җиңә алу мотивы. Кешенең тормыш ихтыяҗы буларак - дөньяны үзәртү . | 4 |
| 15 | **Мөдәррис Әгъләмовның “Каеннар булсаң иде” шигыре** | Мөдәррис Әгъләмовның “Каеннар булсаң иде” шигыре. Көч– идеалларга тугрылыкта. Шигырьдә “тарихи истәлекләр” проблемасының яктыртылышы. Шагыйрь иҗатында жанрлар төрлелеге, стиль үзенчәлекләре. | 4 |
| 16. | **Кабатлау** | 8  нче сыйныфта үтелгәннәрне кабатлау һәм гомумиләштерү | 4 |
| **Барлыгы** | | | **70** |

**9 сыйныф**

| № | Бүлекләр исемлеге | Бүлек, эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Сәнгать төре буларак әдәбият** | Сәнгать төре буларак әдәбият. Сәнгатьнең табигате. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормышның әдәби чагылышы. Әдәбиятның тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып белүгә хезмәт итүе. Әдәбиятның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы | 2 |
| 2. | **Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият** | Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият. Төрки халыклар, татарларның борынгы бабалары турында тарихи-әдәби мәгълуматлар. Борынгы, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының үсеш этаплары. Татар әдәбиятының бер өлеше буларак гомумтөрки әдәбияты һәм фольклоры.Орхон-Енисей истәлекләре. Аларда борынгы төрки халыкларының тарихы, ышануы, әдәби фикерләү үзенчәлекләренең чагылышы. Борынгы төрки фольклорын һәм язма әдәбиятын өйрәнү чыганагы буларак М.Кашгариның “Диване лөгат эт-төрк” әсәре. Й.Баласагунлы “Котадгу белек”–төрки халыкларының беренче классик поэмасы.XII-XIII гасырларда Болгар-татар әдәбияты. К.Гали “Кыйссаи Йосыф”- кеше хисләренең бөеклеге, матурлык, зирәклек гимны.Татар әдәбиятында Яңарыш чоры буларак Алтын Урда әдәбияты . Котб, Сәиф Сараи, Хәрәзми иҗаты. Төрки-татар әдәбиятында суфичылык юнәлеше.Казан ханлыгы чоры әдәбиятына гомуми бәяләмә.Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуы. М.Колыйның фәлсәфи-дидактик хикмәтләрендә татар җәмгыятенең кризис хәленең чагылуы. | 6 |
| 3 | **XIX гасыр татар әдәбияты** | XIX гасыр татар әдәбияты. Г.Курсави, И.Хәлфин, К Насыйри, Ш.Мәрҗәни, Х.Фәизханов, И.Гаспринскийның мәгърифәтчелек эшчәнлеге.Г.Кандалый, Акмулла иҗатында реалистик поэзия формалашу. Татар реалистик прозасы формалашу. | 4 |
| 4 | **З.Бигиев** | Әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү.З.Бигиевнең«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы... Татар халкының үсеш яңарыш кичерүе өчен, мондый темаларның актуаль булуы, татар хатын-кызы язмышы, рус мәдәниятенә йөз тоту. | 6 |
| 5 | **20 гасыр башы татар әдәбияты** | 20 гасыр башы татар әдәбияты. Сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Ф.Әмирханның. «Хәят» повесте. Модернизм, модернизм алымнары. | 5 |
| 6 | **Г.Камал “Банкрот”** | Г.Камал “Банкрот” | 5 |
| 7 | **XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты** | XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты. 1917 елдан соңгы татар әдәбияты үсешендәге кыенлыклар. Эпик төрнең бер жанры буларак романның активлашуы. М.Галәү “Мөһаҗирләр” романы. | 5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | **Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка йогынтысы** | Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка йогынтысы. Сугыә еллары поэзиясенең төп тема-мотивлары, образлары, поэтикасы. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере. Муса Җәлилнең «Тик булса иде ирек» шигыре, “Җырларым”. Ә.Еникинең “Кем җырлады” хикәясе. М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 5 |
| 9 | **1940-50 нче еллар поэзиясендә фәлсәфи-лирик юнәлеш** | Х.Туфан иҗатының чорларга бүленеше. «Кайсыгызның кулы җылы» шигыре. Х.Туфанның «Киек казлар» шигыре. 1940-50 нче еллар поэзиясендә фәлсәфи-лирик юнәлеш. Поэтика һәм стиль үзенчәлекләре. | 6 |
| 10 | **XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты** | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. А.Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» повесте. Татар әдәбиятының милли традицияләргә кайтуы. | 5 |
| 11 | **Тарихи роман. Н. Фәттах** | Тарихи роман. Н. Фәттахның . “Ител суы ака торур» романы | 5 |
| 12 | **XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты** | XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты. XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятының үзгәрүе: совет һәм аннан соңгы чорга тәнкыйди бәя.Зөлфәтнең «Тамыр көлләре»шигыре. Зөлфәтнең«Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигыре | 4 |
| 13 | **Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары** | Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы күзлегеннән ил тормышының аерым этапларын сурәтләүче әдәби әсәрләрнең барлыкка килүе. Ф.Садриевның «Таң җиле» романы. | 4 |
| 14 | **Т.Миңнуллин “Кулъяулык” әсәре** | Халык традицияләрен саклау һәм яңарыш проблемалары. Т.Миңнуллин “Кулъяулык” әсәре. | 4 |
| 15 | **Кабатлау** | 9 нчы сыйныфта үтелгәннәрне кабатлау һәм гомумиләштерү | 2 |
| **Барлыгы** | | | **68** |

**Тематик планлаштыру**
**5 сыйныф**

| № | Бүлекләр | Дәрес темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| **1 нче чирек (16 сәгать)**<br>**Халык авыз иҗаты - 4сәг. Халык авыз иҗатында кыска жанрлар - 4 сәг. Татар фольклорында лирик һәм лиро-эпик жанрлар:җырлар һәм бәетләр - 6 сәг.Татар фольклорында эпик жанрлар: легендалар һәм риваятьләр - 2 сәг.** | | |
| 1 | **Халык авыз иҗаты – 4 сәг.** | Кереш**.** Татар халкының милли, рухи мәдәниятенең байлыгы буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең мөһим өлеше буларак гомумкешелек кыйммәтләре. Фольклор әсәрләренең шигъри үзенчәлекләре: чагыштыру, гәүдәләнеш, метафоралылык , аллегорияле лек. |
| 2 | | Халык авыз иҗаты һәм татар халык фольклоры. Фольклорда дөнья картинасы: геройлык, игелек һәмявызлык, тормыш һәм кеше, кеше һәм табигать турында күзаллау. |
| 3 | | Фольклор әсәрләренең узенчәлекләре. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә образлар системасы. |
| 4 | | Халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләрдә чагыштыру, җанландыру, метафора, аллегория. |
| 5 | **Халык авыз иҗатында кыска жанрлар – 4 сәг.** | Мәкальләр һәм әйтемнәр. Мәкальләрнең килеп чыгышы, идея- тематикасы, аларның әһәмияте |
| 6 | | Табышмаклар.Табышмак жанрының тууы, үсүе, халыкның рухи тормышында әһәмиятле роль уйнавы |
| 7 | | Мәзәкләр**.** Мәзәкләрдәге тапкырлык, юмор |
| 8 | | Мәзәкләр. Мәзәкләрдә кимчелекләрне тәнкыйтьләү, тирән мәгънә, хикмәтлелек |
| 9 | **Татар фольклорында лирик һәм лиро-эпик жанрлар:җырлар һәм бәетләр – 6 сәг.** | Җыр.Халык авыз иҗатында җыр жанры. Татар халык җырларына хас үзенчәлекләр Халык җырларының килеп чыгышы. “Кара урман” җырын тыңлау, анализлау. («Иске кара урман» җыры). |
| 10 | | Җырларны төркемләү.Җырларны төркемнәргә бүлү. Лирик, тарихи, йола җырлары, такмаклар . Озын һәм кыска җырлар. |
| 11 | | Мөнәҗәтләр, аларның үзенчәлекләре |
| 12 | | Бәетләр. Татар фольклорының үзенчәлекле жанры – бәет. Жанр формалаштыру алшартлары. Аларның төрләре . |
| 13 | | “Сак-Сок” бәетен уку, анализлау. Дәрестән тыш уку №1 . Халык җәүһәрләре. Н.Исәнбәт “Балалар фольклоры» китабына күзәтү. |
| 14 | | Б.с.ү. Сочинение. “Сак-сок” бәетендә тасвирланган халык акылы һәм синең үз нәтиҗәләрең” |
| 15 | **Татар фольклорында эпик жанрлар: легендалар һәм риваятьләр – 2 сәг.** | Легендалар һәм риваятьләр турында төшенчә. Аларның килеп чыгышы. |
| 16 | | Риваятьләр.Легендалар. Аларга хас үзенчәлекләр. |
| **2 нче чирек (15 сәгать)**<br>**Татар фольклорында эпик жанрлар: легендалар һәм риваятьләр - 4 сәг. Татар халык әкиятләре (1-4 сыйыфларда үткәнне кабатлау) - 10 сәг. Героик эпос. Дастан жанрының характерлы билгеләре – 1 сәг.** | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 17 | **Татар фольклорында эпик жанрлар: легендалар һәм риваятьләр – 4 сәг.** | “Зөһрә кыз “ легендасын уку һәм анализлау |
| 18 | | “Шәһәр нигә Казан дип аталган” легендасын уку һәм анализлау |
| 19 | | Риваять, легендаларның аермалы һәм охшаш яклары. |
| 20 | | Риваятьләр  һәм легендалар уку һәм аларны анализлау. |
| 21 | **Татар халык әкиятләре(1-4 сыйыфларда үткәнне кабатлау) - 10** | Әкият  турында төшенчә бирү. Әкият төрләре. |
| 22 | | Тылсымлы әкиятләр. “Акбүре” әкиятенең I бүлеген уку, анализлау |
| 23 | | “Акбүре” әкиятенең 2 бүлеген уку, анализлау |
| 24 | | “Акбүре”әкиятендә образлар системасы.<br>Әкият геройларын өйрәнү, аларга бәя бирү |
| 25 | | “Акбүре”әкиятендә образлар  системасы. Йомгаклау. |
| 26 | | Көнкүреш әкиятләре |
| 27 | | Хайваннар турында әкиятләр |
| 28 | | Фольклор әсәрләренең поэтикасы(аерым детальләрдә фантастик яки мифологик сюжет, тормышчанлык, кабатлау, гипербола, литота,каршы кую( антоним) алымнарын куллану) |
| 29 | | Хайваннар турында  әкият сәхнәләштерү. “Төлке һәм торна” әкиятен сәхнәләштерү |
| 30 | | Б.с.ү. Әкият язу |
| 31 | **Героик эпос. Дастан жанрының характерлы билгеләре – 1 сәг.** | Героик эпос турында төшенчә. |
| **3 нче чирек (22 сәгать)**<br>**Героик эпос. Дастан жанрының характерлы билгеләре  - 5 сәг., Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары  - 4 сәг.,  Фольклор һәм әдәби әкият  - 6 сәг.,  Г.Тукайның романтик шигырьләрендә туган җиргә дан җырлау - 5 сәг.** | | |
| 32 | **Героик эпос.** | Дастан турында төшенчә. |

| | | |
|---|---|---|
| 33 | **Дастан жанрының характерлы билгеләре – 5 сәг.** | Алыплар турында дастаннар |
| 34 | | Тарихи дастаннар |
| 35 | | Дастаннар уку һәм аларны анализлау. |
| 36 | | Әкият геройлары белән дастан геройлары |
| 37 | **Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары – 4 сәг.** | Татар халык авыз иҗаты һәм башка халыклар фольклорының аваздашлыгы һәм аермалары. Татар халык авыз иҗатын башка халыклар фольклоры белән чагыштыру |
| 38 | | Әдәбиятның барлыкка килүе.Татар әдәбиятының фольклор һәм ислам мифологиясе белән бәйләнеше |
| 39 | | Ф. Әмирханнын “Ай өстендәге Зөһрә кыз” хикәясен уку. Игелек һәм явызлык гәүдәләндерү. |
| 40 | | Ф. Әмирханнын “Ай өстендәге Зөһрә кыз” хикәяседә персонажлар системасы. Бара торган вакыйгаларга автор аңлатмалары |
| 41 | **Фольклор һәм әдәби әкият – 6 сәг.** | Фольклор һәм әдәби әкият .Сәнгать уйдырмалары (вымысел). Әдәби әкиятләр. Аларның халык авыз иҗатына нигезләнеп иҗат ителүе |
| 42 | | Г.Тукай .“Шүрәле” поэмасын уку. |
| 43 | | Г.Тукай .“Шүрәле” поэмасын анализлау, автор идеясын һәм мотивын билгеләү |
| 44 | | Г.Тукай .“Шүрәле” поэмасын татар халык әкияте белән чагыштыру. Троп турында төшенчә бирү. “Шүрәле” поэмасына отзыв (бәя) язу |
| 45 | | Татар халык әкиятләрен Г.Тукай язган вариантлар белән чагыштыру. ( “Кәҗә белән Сарык” әкияте). Дәрестән тыш уку №3. Әдәби әкиятләр. “Кошларда да кеше язмышлары” Җ. Тәрҗеманов “Тукран малае Шуктуган” |
| 46 | | Б.с.ү. Сочинение. Әдәби әкиятләрдә табигать һәм кеше образларына салынган фикерләр, нәтиҗәләр (өйрәнгән әсәрләр мисалында) . |
| 47 | **Г.Тукайның романтик шигырьләрендә туган җиргә дан җырлау – 5 сәг.** | .Г. Тукай. “Пар ат” шигырен уку. Казанга сәфәрне әкияти рәвештә торгызу. Казан һәм туган җир мифологиясе. |
| 48 | | Г. Тукай. “Пар ат” шигырен анализлау. Г.Тукайның романтик шигырендә туган җиргә дан җырлау. |
| 49 | | Г. Тукайнын “Пар ат”шигыре. Шигырьдә лексик һәм фонетик нәфис сүз чаралары. |
| 50 | | Г. Тукай.“Туган җиремә” шигырен уку. Шигырьдә лексик һәм фонетик нәфис сүз чаралары. |
| 51 | | Г. Тукай.“Туган җиремә” шигырен анализлау. Г.Тукайның романтик шигырендә туган җиргә дан җырлау. |
| 52 | **М.Гафури “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле – 2 сәг.** | Мәсәл турында төшенчә. Мәсәл жанры. Мәсәлдә аллегорик образлар |
| 53 | | М.Гафури “Сарыкны кем ашаган?” мәсәлен уку |

| | | |
|---|---|---|
| **4 нче чирек ( 17 сәгать)**<br>**М.Гафури “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле (2 сәг.) Ш.Галиев. (4 сәг.) Ф.Яруллин (4 сәг.) 5 нче сыйныфта өйрәнгәнәрне кабатлау һәм гомумиләштерү ( 7 сәг.)** | | |
| 54 | **“Сарыкны кем ашаган?” мәсәле – 2 сәг.** | М.Гафури “Сарыкны кем ашаган?” мәсәлен анализлау. Образлар. |
| 55 | | М.Гафури “Сарыкны кем ашаган?” мәсәленә аннотация язу |
| 56 | **Ш.Галиев. – 4 сәг.** | Ш.Галиев. “Һәркем әйтә дөресен” шигырен уку |
| 57 | | Ш.Галиев. “Һәркем әйтә дөресен” шигырен анализлау |
| 58 | | Ш.Галиев шигырьләрендә юмор. |
| 59 | | Балалар әдәбияты. Юмор һәм сатира турында төшенчә бирү |
| 60 | **Ф.Яруллин – 4 сәг.** | Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигырен уку |
| 61 | | Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигырен анализлау<br>Лирик герой образы. |
| 62 | | Шигырь, строфа, ритм, рифма, шигырь төзелеше төшенчәләре. Ф.Яруллин шигырьләрендә ритм, рифманы билгеләү |
| 63 | | Ф.Яруллин шигырендә сурәтләү чаралары ярдәмендә лирик герой бирлеше. Шигырь язып карау |
| 64 | **5 нче сыйныфта өйрәнгәнәрне кабатлау һәм гомумиләштерү – 7 сәг.** | 5 нче сыйныфта өйрәнгән әдәбият теориясе материалларын кабатлау. Сочинениягә әзерлек. Язма эшләрне караламада редакцияләү |
| 65 | | **“Минем туган җирем” дигән темага контроль сочинение .** |
| 66 | | Сочинениеләрне анализлау. Хаталар өстендә эш. |
| 67 | | Кабатлау. 5 нче сыйныфта өйрәнгән әсәрләргә бәя, аннотация язу күнегүләре. |
| 68 | | Кабатлау. 5 нче сыйныфта өйрәнгән әсәрләргә рецензия язу күнегүләре. |
| 69 | | “Фольклор һәм әдәби әкият” бүлеген кабатлау |
| 70 | | Вакытлы матбугат басмалары. Дәрестән тыш уку №4.<br>Балалар өчен чыгарылган газета журналларга күзәтү ясау |

## 6 сыйныф

| № | Бүлекләр | Дәрес темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|

| 1 нче чирек (17 сәгать)<br>Фольклорның эпик жанрларын кабатлау – 4 сәг. Мифлар – 6 сәг. Әдәбиятта мифологик һәм дини сюжетларның үсеше – 6 сәг. | | |
|---|---|---|
| 1 | **Фольклорның эпик жанрларын кабатлау – 4 сәг.** | Бәетләр. |
| 2 | | Әкиятләр. |
| 3 | | Риваять. |
| 4 | | Легендалар. Метафора, аллегория. |
| 5 | **Мифлар - 6 сәг.** | Дөньяны үзләштерүнең беренче баскычы буларак мифология. Мифларның барлыкка килүе. |
| 6 | | Мифлар белән танышу. |
| 7 | | «Алып кешеләр» мифы. Уку һәм фикер алышу. |
| 8 | | «Җил иясе җил чыгара» мифы. Уку һәм анализлау. |
| 9 | | Дөнья халыклары тудырган мифлар һәм татар халкы иҗат иткән мифлар. |
| 10 | | Мифларны классификацияләү. |
| 11 | **Әдәбиятта мифологик һәм дини сюжетларның үсеше - 7 сәг.** | Каюм Насыйриның (1825-1902) әдәби һәм фәнни эшчәнлеге. Фольклор, этнография, әдәбият, татарлар тарихы. |
| 12 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. Әсәрнең язылу тарихы. |
| 13 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. «Гыйлем эстәп, ерак юлга» бүлеген уку. |
| 14 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. «Әбүгалисина Мисыр шәһәрендә», «Әбелхарисның Багдад патшасында хезмәте» бүлекләрен уку. |
| 15 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. «Әбелхарисның Мисырга килүе һәм Әбүгалисинага каршы көрәше», «Комсызлык бәласе» бүлекләрен уку. |
| 16 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. «Сарай һаман тынычланмады», «Әбүгалисина – патша сараенда» бүлекләрен уку. |
| 17 | | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. «Әбелхарис патша алдында үзен акламакчы була», «Хәлвәфрүшнең патша кызына өйләнүе» бүлекләрен уку. |

| | | |
|---|---|---|
| **2 нче чирек (14 сәгать)**<br>**Әдәбиятта мифологик һәм дини сюжетларның үсеше – 3 сәг. Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе: шартлылык – 4 сәг. Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар» хикәясе – 6 сәг. Габдулла Тукай. Автобиографик повесть «Исемдә калганнар» - 1 сәг**. | | |
| 18 | **Әдәбиятта мифологик һәм дини сюжетларның үсеше - 3 сәг**. | К. Насыйри «Әбүгалисина» повесте. Әсәрдә фантастик сюжет һәм мәгърифәтчелек идеяләре. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. |
| 19 | | Фикер алышу өчен тема: Әбүгалисина образы – тарихи персонаж, әкияти герой яки мәгърифәтчелек идеалымы? |
| 20 | | К.Насыйриның "Әбүгалисина" әсәре буенча инша язу. |
| 21 | **Фольклор жанрларының әдәбиятка күчүе: шартлылык – 4 сәг.** | Г. Рәхим «Яз әкиятләре» . Автор турында мәгълүмат. |
| 22 | | Г. Рәхим «Яз әкиятләре» . Әсәрнең эчтәлеге белән танышу. |
| 23 | | Аллегорик образлылык. Персонаж исеменнән сөйләү. |
| 24 | | Мөһим кешелек сыйфаты буларак, риясызлык. Эпик жанр - хикәя. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Эчтәлек:<br><br>вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. |
